ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау авылында
2023 елда үзара салым кертү турында

2022 елның 17 октябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау авылында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәрбер гражданнан, көндезге бүлектә укучы студентлар, сугыш ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзалары, 1 нче төркем инвалидлардан тыш, 500 сум күләмендә 2023 нче елда үзсалым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Яшьләр урамы, Дуслык урамы, Тынычлык урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- юлларны грейдлау (килешү буенча түләү).

3. Тубылгы Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф. Исмәгыйлев

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ТУБЫЛГЫТАУСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ
р/06-597/14
СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ